

# ЧИШМӘ БАШЫ

№2 2024 ел
декабрь

*Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
«Арча 8нче балалар бакчасы»
муниципаль бюджет
мәктәпкәчә белем бирү
учреждениесе*

2024 гаилә елы

Ата –аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү

Бу санда:

- Яңа ел теләкләре
- Бакчабыз яңалыклары
- Яңа ел мизгелләре
- Кошларга ярдәм итү
- Ата-аналарга белешмәлек

## ЯҢА ЕЛ БЕЛӘН!

### Бакчабыз яңалыклары

- Логопед Алсина Хаҗиәхмәт кызы "Логопедик копилка" Бөтенроссия методик эшләнмәләр конкурсында катнашты һәм 2 урынны яулады.
- Хөснулла исемендәге Саба балалар сәнгать мәктәбе базасында "Бәләкәчләр аланы" республика иҗат конкурсында Гыйльмуллина Фәридә чыгыш ясады һәм дипломга лаек.
-Мәктәпкә әзерлек төркемендә шагыйрә Дилә Абдуллина иҗатына багышланган "Чәчәкләр сере" исемле музыкаль-әдәби очрашу кичәсе узды.
-Ләйсән Фәнис кызы "Ел тәрбиячесе 2025" һөнәри конкурсының муниципаль этабында "Иң иҗади педагог" номинациясендә җиңүче булды.
- Чулпан Фирдинанд кызы "Ел тәрбиячесе-2025" муниципаль һөнәри конкурсының муниципаль этабында катнашты һәм 3 урынны яулады.




## Кадерле дуслар!

Сезне чын күңелдән якынлашып килүче Яңа 2025нче ел белән котлыйбыз! Тагын бер елны тарихта калдырып алга атлыйбыз, үткәннәргә нәтиҗәләр ясыйбыз. Киләчәктә куйган максатларга тугры калып, яңадан-яңа уңышларга ирешергә язсын, күңелләребездә ышаныч уты сүнмәсен. Яңа ел һәр йортка иминлек, гаиләләргә тынычлык, муллык һәм бәхет-шатлыклар китерсен иде! Сезнең һәрберегезгә рух ныклыгы, күңел көрлеге һәм сәламәтлек телибез. Ил-көнебез тыныч, барыр юлларыбыз киң, туар таңнарыбыз имин булсын. 2025нче ел яңа бәхетләр белән килсен. Яңа еллар мөбарәк булсын!

Балалар бакчасы хезмәткәрләре














**Балалар бакчасында Яңа Ел бәйрәмнәренең тылсымы.**

Иң матур һәм әкияти бәйрәм алдыннан безнең балалар бакчасында «Иң матур фотозона» конкурсы игълан ителде. Быел педагоглар үзләренең искиткеч ярдәмчеләре, ата-аналары һәм балалары белән каминнар, бүләкләр, Яңа ел чыршылары, йолдызлар, кар бабайлар, ел символы һәм әкияти өйләр белән Яңа ел фотозоналарын оештырдылар. Фотозоналарга күз салсак, аларда креативлык һәм фантазия кулланганнары күренеп тора. Ә нәтиҗәләрне бакчабызның җитәкчелеге ясады.Әмма конкурсның иң төп нәтиҗәсе ирешелде, балалар өчен тылсымлы, әкияти могҗиза атмосферасы барлыкка килде. Без чын күңелдән шушы искиткеч яңа ел әкиятен иҗат иткән әти-әниләребезгә, Яңа елны каршылауның иң истәлекле, иң кызыклы мизгелләрен фотога төшерү мөмкинлеген тудырган өчен рәхмәт белдерәбез. Конкурста катнашучыларны котлыйбыз һәм аларга киләсе елда җиңүләр телибез! Барыгызны да Яңа ел белән! Могҗизага ышаныгыз!

Декабрь башыннан бакчаның һәр почмагы бәйрәмгә әзерлек рухы белән тула. Балалар бакчасындагы Яңа ел бәйрәмнәре тылсымы балаларның йөрәкләрен шатлык һәм могҗиза көтү белән тутыра. Ел саен без бакчабызның күңелле маҗаралар белән тулы әкияти урынга әверелүен түземсезлек белән көтәбез.
Елның иң көтелгән бәйрәме алдыннан безнең балалар бакчасында, традиция буенча, яңа ел бәйрәмнәре узды. Бу бәйрәм һәркем өчен дә әһәмиятле, ул әкияткә ышанырга, нинди дер гаҗәеп, серле, мавыктыргыч һәм, һичшиксез, онытылмаслык бер атмосферага чумарга дәртләндерә. Яңа ел бәйрәмнәре көннәрендә балалар спектакльләрдә рәхәтләнеп катнаштылар, анда алар әкият геройлары булдылар. Көлке һәм күңелне нечкәртерлек мизгелләр, җырлар, биюләр һәм уеннар үзенчәлекле атмосфера ясады . Һәр тамаша ахырында балалар янына зур капчык тулы бүләкләр алып Кыш бабай килде.
Балалар бакчасында Яңа Ел бәйрәмнәренең тылсымы-якты мизгелләр генә түгел, ә игелек, дуслык һәм үзара ярдәмләшү турында мөһим дәресләр дә ул. Бу хатирәләр балаларның йөрәгендә озак еллар сакланып кала, могҗизага ышануның һәм тирә-юньдәгеләр белән шатлык уртаклашуның мөһимлеген искә төшерә.















## *Кышын кошларга ничек ярдәм итәргә?*

  

Бөҗәкләр белән туклана торган кошлар өчен кыш белән бергә авыр вакытлар да килә, чөнки елның бу вакытында алар бөҗәкләр таба алмый. Гомумән, кошларга ризык табу бик авырлаша, шуңа күрә аларның күбесе язга кадәр яши алмый. Безнең барыбызга да урамда, паркта, хәтта үз балконыбызда, тәрәзә артында кошларны ашату өчен җимлекләр кую турында уйланырга кирәк.Сорау туа: кошларны, аерым алганда, песнәкләрне нәрсә белән тукландырырга соң?

1. Көнбагыш орлыклары
2. Терлек мае
3. Тары
4. Атланмай
5. Төрле ярмалар
6. Эремчек
7. Кишер
8. Икмәк

Кошлар, бигрәк тә кышын, үзләрен ашатучыга бик тиз ияләшәләр. Шуңа күрә өйрәнелгән җимлекләрендә азык таба алмасалар, алар башка урынга азык эзләп китә. Бигрәк тә кичке якта һәм көчле салкыннарда ияләшкән җимлекләрендә азык булмаса, алар ач калырга һәм туңып үләргә мөмкиннәр. Шуңа күрә ризыкны даими рәвештә куярга кирәк, әгәр дә андый мөмкинлегегез юк икән, терлек мае элеп куярга тырышыгыз, ул тиз бетми һәм туклыклыгы буенча да югары. Иң мөһиме — кошларга салкын кышта булышырга теләк булуы, аларны тәмле һәм файдалы тукландыру өчен һәрвакыт төрле вариантлар табарга мөмкин!

## Яңа ел каникулларында балаларның иминлеге турында ата-аналарга (законлы вәкилләргә)белешмәлек.

### ХӨРМӘТЛЕ ӘТИ-ӘНИЛӘР!

Яңа ел бәйрәмнәре  һәм кышкы каникуллар якынлаша. Балалар өчен иң гаҗәеп вакыт: чыршы, бүләкләр, төрле күңел ачулар, бенгал утлары, шарлаткычлар, петардалар, кар таулары, бозлыклар, чаналар, чаңгы һәм тимераяклар — болар барысы да шатлык китереп кенә калмый, җәрәхәтләр һәм пешүләр аркасында күңелсезләнергә дә мөмкин. Кышкы бәйрәмнәрдә баланың иминлеген оештыруда ярдәм итәсе килә. Гади һәм аңлаешлы кагыйдәләр сезгә тормышны һәм сәламәтлекне саклап калырга һәм кыштан бары тик уңай хис-кичерешләр генә алырга ярдәм итәчәк.

### Ата-аналарга үтенеч

-балаларны өйдә ялгыз калдырмагыз;
-балалар җәрәхәтләнә ала торган барлык предметларны алып куегыз;
-шырпы, зажигалкаларны балалар өчен уңайлы урында калдырмагыз;
-дарулар балалар өчен мөмкин булмаган урында сакланырга тиеш;
-балаларны караусыз бозга (балык тотарга, чаңгыда һәм чанада шуарга) җибәрмәгез;
-балаларга тәүлекнең караңгы вакытында, өйдән ерак йөрергә рөхсәт итмәгез;
-аларга плитә белән мөстәкыйль файдаланырга, электр приборларын, шул исәптән электр гирляндасын кабызырга рөхсәт итмәгез;
-балаларга янгын куркынычсызлыгы турында сөйләгез;
-янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүгә бәйле барлык очракларда да үрнәк булыгыз!

Исегездә тотыгыз! Балаларның иминлеге-ата-аналарның бурычы!